ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.12, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Совет мәйданы, 12 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-00-44, факс (84366)3-11-44. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**КАРАР**

**«08» «ноябрь» 2021 ел** **№ 1192**

**2022 елга Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының балаларга өстәмә белем бирүче мәгариф оешмаларының туристлык-туган якны өйрәнү, экология-биология, хәрби-патриотлык, социаль-педагогик, социаль-икътисади, табигый-фәнни, техник һәм культурология юнәлешендә өстәмә белем бирү һәм балаларга өстәмә белем бирү буенча күппрофильле мәгариф оешмаларының норматив чыгымнарын раслау турында**

Россия Федерациясенең 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы «Мәгариф турында» Законының 99 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 1 өлешенең 11 пункты, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2009 елның 31 декабрендәге 939 номерлы «Балаларга өстәмә белем бирү учреждениеләрен туристлык-туган якны өйрәнү, экология-биология, хәрби-патриотлык, социаль-педагогик, социаль-икътисади, табигый-фәнни, техник һәм культурология юнәлешендә һәм балаларга өстәмә белем бирү буенча күппрофильле мәгариф учреждениеләрен финанслауның нормативларын исәпләү турында Нигезләмәне раслау хакында» карарына һәм Арча муниципаль районы Уставына нигезләнеп, Арча муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. 2022 елга кушымта итеп бирелгән:

2022 елга Арча муниципаль районының балаларга өстәмә белем бирүче мәгариф оешмаларының туристлык-туган якны өйрәнү, экология-биология, хәрби-патриотлык, социаль-педагогик, социаль-икътисади, табигый-фәнни, техник һәм культурология юнәлешендә һәм балаларга өстәмә белем бирү буенча күппрофильле мәгариф оешмаларының программаларын гамәлгә ашыруга норматив чыгымнарын;

балаларга өстәмә белем бирү оешмаларында балаларга туристлык-туган якны өйрәнү, экология-биология, хәрби-патриотлык, социаль-педагогика, социаль-икътисадый, табигый-фәнни, техник һәм культурология юнәлешендәге

өстәмә белем бирү оешмаларында һәм балаларга өстәмә белем бирү күппрофильле мәгариф оешмаларында өстәмә белем бирү программаларын гамәлгә ашыруга норматив чыгымнарга карата төзәтү коэффициентын 0,5 күләмендә расларга.

2. «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы финанс-бюджет палатасы» муниципаль казна учреждениесенә:

әлеге карарның 1 пунктында расланган балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларының норматив чыгымнары нигезендә балаларга өстәмә белем бирү буенча мәгариф оешмаларын финанслауны;

әлеге карарның 1 пунктында расланган балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларының норматив чыгымнарын яңадан карауны өстәмә белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт хакын хезмәт законнарында һәм башка норматив хокукый актларда билгеләнгән тәртиптә индексацияләү белән бер үк вакытта тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http:pravo.tatarstan.ru) яки Арча муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2022 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Арча муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Э.Ш.Вафинага йөкләргә.

Башкарма
комитет җитәкчесе Р.Р.Мөхәрәмов

Арча муниципаль районы
Башкарма комитетының
08.11. 2021ел, № 1192
карары белән расланды

**2022 елга Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының балаларга өстәмә белем бирүче мәгариф оешмаларының туристлык-туган якны өйрәнү, экология-биология, хәрби-патриотлык, социаль-педагогик, социаль-икътисади, табигый-фәнни, техник һәм культурология юнәлешендә өстәмә белем бирү һәм балаларга өстәмә белем бирү буенча күппрофильле мәгариф оешмаларының норматив чыгымнары**

| Өстәмә белем бирү программасының юнәлеше | Территория ягыннан урнашуы | 1 укучыга елына норматив чыгымнар, сумнарда | | |
|---|---|---|---|---|
| | | беренче уку елы | икенче ел уку | өченче һәм аннан соңгы уку еллары |
| Сәнгать-эстетик | шәһәр җирлеге | 5 569 | 10 314 | 12 376 |
| | авыл җирлеге | 5 970 | 11 055 | 13 266 |
| Физкультура-спорт | шәһәр җирлеге | 5 468 | 10 126 | 12 151 |
| | авыл җирлеге | 5 868 | 10 867 | 13 041 |
| Техник иҗат | шәһәр җирлеге | 5 873 | 10 876 | 13 051 |
| | авыл җирлеге | 6 273 | 11 617 | 13 940 |
| Туристлык һәм туган якны өйрәнү | шәһәр җирлеге | 5 671 | 10 501 | 12 601 |
| | авыл җирлеге | 6 071 | 11 242 | 13 491 |
| Экология-биология | шәһәр җирлеге | 5 671 | 10 501 | 12 601 |
| | авыл җирлеге | 6 071 | 11 242 | 13 491 |
| Хәрби-патриотлык | шәһәр җирлеге | 5 671 | 10 501 | 12 601 |
| | авыл җирлеге | 6 071 | 11 242 | 13 491 |
| Социаль-педагогик | шәһәр җирлеге | 5 266 | 9 751 | 11 702 |
| | авыл җирлеге | 5 666 | 10 493 | 12 591 |
| Социаль-икътисади | шәһәр җирлеге | 5 266 | 9 751 | 11 702 |
| | авыл җирлеге | 5 666 | 10 493 | 12 591 |
| Табигый-фәнни | шәһәр җирлеге | 5 671 | 10 501 | 12 601 |
| | авыл җирлеге | 6 071 | 11 242 | 13491 |